## ГҮЗӘЛИЯ

*сүзләре һәм көе – Шамил Сагаутдинов*

1. Безнең авыл – тау башында.
Тирәкләре күккә тия.
Бер чибәр кыз яши монда.
Исеме аның – Гүзәлия.

Чәче бигрәк матур була,
Җилфердәтеп бер тараса.
Күңелемә рәхәт була,
Елмаеп караса!

**Кушымта:**

Гүзәлия, Гүзәлия!
Бөтен кеше аны сөя.
Сәләтләре чиксез аның,
Тырышлыгы – биниһая!

Гүзәлия, Гүзәлия!
Күзе – шомырт, ирене – чия.
Йөрәккәемдә ут кабынды, } 2 тапкыр
Гүзәлия дия, дия!

2. Гүзәлияне очратсам,
Бар кайгыларым тарала.
Гүзәлиягә сүз катсам,
Күңелем сафлыкка урала!

Гүзәлия, алсу гөлем!
Нур сибелсен юлларыңа!
Алсу гөлем, саф күңелем
Бүләк итәм сиңа!

**Кушымта.**

**Гузелия**

Посвящается девушкам по имени Гузелия, Гузель.

*Гузелия, Гузелия!*
*Под стать луне краса твоя!*
*С тех пор, как я тебя увидел,*
*Горит огнем душа моя!*